КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 26 июль г.Казань № 645

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы кайбер типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 июль, 611 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1183 нче; 2013 ел, 30 гыйнвар, 48 нче; 2013 ел, 11 май, 313 нче; 2013 ел, 29 июнь, 455 нче; 2014 ел, 10 гыйнвар, 2 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 20 нче; 2014 ел, 28 май, 362 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 25 август, 613 нче; 2014 ел, 6 октябрь, 726 нчы; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1050 нче; 2015 ел, 4 август, 565 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1025 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 611 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 983 нче; 2017 ел, 18 май, 292 нче; 2017 ел, 27 сентябрь, 731 нче; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2017 ел, 31 октябрь, 827 нче; 2017 ел, 11 ноябрь, 885 нче; 2018 ел, 22 гыйнвар, 27 нче; 2018 ел, 26 апрель, 293 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 953 нче; 2018 ел, 27 декабрь, 1247 нче; 2019 ел, 13 июль, 578 нче; 2019 ел, 28 август, 730 нчы; 2019 ел, 18 октябрь, 938 нче; 2019 ел, 29 октябрь, 967 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1176 нчы; 2020 ел, 28 май, 433 нче; 2020 ел, 29 июнь, 539 нчы; 2020 ел, 8 июль, 568 нче; 2021 ел, 4 февраль, 54 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы бертип булмаган кайбер учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.5 пункт өстәргә:

«1.5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы дәүләт медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы бертип булмаган кайбер учреждениеләр җитәкчеләре:

белем алу һәм эш (белгечлек буенча, билгеле бер вазифада эшләү) стажы турындагы документларны һәм хезмәткәрләрнең хезмәт окладлары күләмнәре билгеләнә торган башка нигезләрне тикшерә;

ел саен оешмалар хезмәткәрләре өчен тарификацияле исемлекләр төзи һәм аларны раслый;

хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләмнәрен үз вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җавап бирә.»;

4 бүлектә:

4.2.8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2.8. Премия акчасы һәм кызыксындыру характерындагы башка түләүләр билгеле бер вакыт чоры (ай, квартал, ел) өчен, шул исәптән бер тапкыр, юбилей даталарына, мактау билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу белән бәйле рәвештә һәм оешмаларның локаль актларында һәм күмәк шартнамәләрдә билгеләнгән башка нигезләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы бертип булмаган кайбер учреждениеләрнең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифалары һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә билгеләнергә мөмкин.

Премия акчасын һәм кызыксындыру характерындагы башка түләүләрне түләү күләмнәре, тәртибе һәм шартлары оешманың локаль актларында һәм күмәк шартнамәләрендә билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.2.9 пунктча өстәргә:

«4.2.9. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы бертип булмаган кайбер учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

4.3.6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3.6. Премия акчасы һәм кызыксындыру характерындагы башка түләүләр билгеле бер вакыт чоры (ай, квартал, ел) өчен, шул исәптән бер тапкыр, юбилей даталарына, мактау билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу белән бәйле рәвештә һәм оешмаларның локаль актларында һәм күмәк шартнамәләрдә билгеләнгән башка нигезләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы бертип

булмаган кайбер учреждениеләрнең сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазифалары һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә билгеләнергә мөмкин.

Премия акчасын һәм кызыксындыру характерындагы башка түләүләрне түләү күләмнәре, тәртибе һәм шартлары оешманың локаль актларында һәм күмәк шартнамәләрендә билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.3.7 пунктча өстәргә:

«4.3.7. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы бертип булмаган кайбер учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.5.8 пунктча өстәргә:

«4.5.8. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы бертип булмаган кайбер учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында «Республика махсуслаштырылган бала йорты» дәүләт бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең мәгариф хезмәткәрләре вазифалары һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

7 бүлектә:

исемендә «формалаштыру» сүзеннән соң «һәм алардан файдалану» сүзләрен өстәргә;

7.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.7. Катаракта белән авыручыларга, «эластик интраокуляр линзалар имплантацияләнә торган катаракта микроинвазив энергетик хирургиясе» операциясен кулланып, югары технологияле медицина ярдәме һәм медицина ярдәме күрсәтүче дәүләт оешмаларында әлеге медицина ярдәме төрләрен күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина персоналына (операция ясаучы бригада составына, авыруга турыдан-туры хезмәт күрсәтүче табиб һәм урта медицина персоналына) стимул бирү характерындагы түләүләр фонды формалаштырыла.

Стимул бирү характерындагы түләүләр фонды тиешле финанс елына катаракта белән авыручыларга, «эластик интраокуляр линзалар имплантацияләнә торган катаракта микроинвазив энергетик хирургиясе» операциясен кулланып, югары технологияле медицина ярдәме, медицина ярдәме күрсәтүгә план йөкләмәсен финанс белән тәэмин итү күләме чикләрендә формалаштырыла һәм әлеге күләмнең 11 процентыннан арта алмый.»;

7.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.8. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы бертип булмаган кайбер учреждениеләрнең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын яки бюджет сметасын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча медицина оешмасының бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы булганда, кызыксындыру характерындагы түләүләр кайсы вазифаларның һөнәр-квалификация төркеме буенча хезмәт өчен түләү фондында экономияләнгән акча барлыкка килгән булса, шул вазифалар төркемендәге хезмәткәрләргә (эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен кертеп) түләнә.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән медицина оешмасының хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәренә («Республика махсуслаштырылган бала йорты» дәүләт бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен биләүче хезмәткәрләрдән, мәгариф хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләреннән, медицина оешмасының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы бертип булмаган учреждениенең сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләреннән, җитәкчесеннән тыш) бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме, әлеге чор өчен эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып, агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.

Медицина оешмасы җитәкчесенә хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән кызыксындыру характерындагы түләү күләме медицина оешмасының гамәлгә куючысы тарафыннан билгеләнә.

Хезмәт өчен түләү фондында медицина оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын яки бюджет сметасын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләп барлыкка килгән акчаны файдалану өчен җаваплылык медицина оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче; 2013 ел, 29 июнь, 458 нче; 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы; 2014 ел, 15 февраль, 91 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 июль, 553 нче; 2014 ел, 2 август, 565 нче; 2014 ел, 10 октябрь,

752 нче; 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче; 2015 ел, 2 апрель, 209 нчы; 2015 ел, 22 июль, 536 нчы; 2015 ел, 3 ноябрь, 833 нче; 2016 ел, 26 май, 356 нчы; 2016 ел, 30 июнь, 449 нчы; 2017 ел, 16 март, 144 нче; 2017 ел, 20 июнь, 400 нче; 2017 ел, 5 сентябрь, 636 нчы; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2018 ел, 14 июнь, 482 нче; 2018 ел, 15 июнь, 486 нчы; 2018 ел, 16 ноябрь, 998 нче; 2019 ел, 17 июль, 594 нче; 2019 ел, 28 август, 715 нче; 2019 ел, 22 октябрь, 952 нче; 2019 ел, 6 декабрь, 1110 нчы; 2021 ел, 2 апрель, 212 нче; 2021 ел, 10 апрель, 237 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.4 пункт өстәргә:

«1.4. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре җитәкчеләре:

белем алу һәм эш (белгечлек буенча, билгеле бер вазифада эшләү) стажы турындагы документларны һәм хезмәткәрләрнең хезмәт окладлары күләмнәре билгеләнә торган башка нигезләрне тикшерә;

ел саен Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре өчен тарификацияле исемлекләр төзи һәм аларны раслый;

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмнәрен үз вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җавап бирә.»;

6 бүлектә:

6.2.5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2.5. Премия акчасы һәм кызыксындыру характерындагы башка түләүләр билгеле бер вакыт чоры (ай, квартал, ел) өчен, шулай ук бер тапкыр, юбилей даталарына, мактау билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу белән бәйле рәвештә һәм оешманың локаль актларында һәм күмәк шартнамәләрдә билгеләнгән башка нигезләр буенча социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә билгеләнергә мөмкин.

Премия акчасын һәм кызыксындыру характерындагы башка түләүләрне түләү күләмнәре, тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең локаль актларында һәм күмәк шартнамәләрендә билгеләнә.»;

6.2.7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2.7. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазифаларының һөнәр-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә

төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле 6.2.8 пунктча өстәргә:

«6.2.8. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын яки бюджет сметасын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазифаларының һөнәр-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.»;

6.3.5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3.5. Премия акчасы һәм кызыксындыру характерындагы башка түләүләр билгеле бер вакыт чоры (ай, квартал, ел) өчен, шул исәптән бер тапкыр, шулай ук юбилей даталарына, мактау билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу белән бәйле рәвештә һәм оешманың локаль актларында һәм күмәк шартнамәләрдә билгеләнгән башка нигезләр буенча мәгариф хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә билгеләнергә мөмкин.

Премия акчасын һәм кызыксындыру характерындагы башка түләүләрне түләү күләмнәре, тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең локаль актларында һәм күмәк шартнамәләрендә билгеләнә.»;

6.3.7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3.7. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «2012 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә эш итүләрнең илкүләм стратегиясе турында» 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы, «Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру буенча кайбер чаралар турында» 2012 ел, 28 декабрь, 1688 нче указларында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында балалар һәм яшүсмерләр өчен дәүләт социаль приютлары, акыл үсеше артта калган балалар интернат йортлары мәгариф хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркеме хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле 6.3.8 пунктча өстәргә:

«6.3.8. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын яки бюджет сметасын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт

күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә мәгариф хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.»;

6.4.6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.4.6. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын яки бюджет сметасын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемендәге хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәргә әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.»;

6.5.6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.5.6. Премия акчасы һәм кызыксындыру характерындагы башка түләүләр медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә билгеле бер вакыт чоры (ай, квартал, ел) өчен, шул исәптән бер тапкыр, шулай ук юбилей даталарына, мактау билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу белән бәйле рәвештә һәм оешманың локаль актларында һәм күмәк шартнамәләрдә билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеләнергә мөмкин.

Премия акчасын һәм кызыксындыру характерындагы башка түләүләрне түләү күләмнәре, тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең локаль актларында һәм күмәк шартнамәләрендә билгеләнә.»;

6.5.8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.5.8. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле 6.5.9 пунктча өстәргә:

«6.5.9. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын яки бюджет сметасын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.»;

6.6.7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.6.7. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын яки бюджет сметасын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемендәге хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәргә әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.»;

6.7.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.7.7. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын яки бюджет сметасын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемендәге хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәргә әлеге тиешле

чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.»;

8 бүлектә:

8.5 пунктта:

дүртенче – бишенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 8.5.1 пунктча өстәргә:

«8.5.1. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын яки бюджет сметасын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.»;

8.6 пунктта:

дүртенче – бишенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

9 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмасының һәм дәүләт социаль яклау учреждениесенең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм алардан файдалану тәртибе

9.1. Бюджет яки автоном учреждение булып торган халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмасында хезмәт өчен түләү фонды агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган норматив чыгымнарны, хезмәт күрсәтүләр күләмнәрен исәпкә алып билгеләнгән акча күләме чикләрендә формалаштырыла һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

Татарстан Республикасының казна учреждениеләре булып торган халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмасында һәм дәүләт социаль яклау учреждениесендә хезмәт өчен түләү фонды агымдагы финанс елына оешманың (учреждениенең) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән иң чик штат саныннан, бу карарда билгеләнгән хезмәт окладлары, стимул һәм компенсация бирү характерындагы түләүләр күләмнәреннән чыгып билгеләнгән акча күләме

чикләрендә формалаштырыла һәм тиешле казна учреждениесенең бюджет сметасында чагылдырыла.

9.2. Бу Нигезләмәдә билгеләнгән хезмәт окладларын, компенсация, стимул бирү һәм социаль характердагы түләүләрне исәпләү Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә (эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен кертеп) Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында һәм бюджет сметасында агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

9.3. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын яки бюджет сметасын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы булганда, кызыксындыру характерындагы түләүләр кайсы вазифаларның һөнәр-квалификация төркеме буенча хезмәт өчен түләү фондында экономияләнгән акча барлыкка килгән булса, шул вазифалар төркемендәге хезмәткәрләргә (эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен кертеп) түләнә.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәренә (сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазифаларының, балалар һәм яшүсмерләр өчен дәүләт социаль приютлары, акыл үсеше артта калган балалар интернат йортлары мәгариф хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен биләүче хезмәткәрләреннән, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләреннән, оешма җитәкчесеннән тыш) әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре җитәкчеләренә кызыксындыру характерындагы түләү күләме гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмасының һәм дәүләт социаль яклау учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын яки бюджет сметасын үтәү барышында хезмәт өчен түләү фондында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәре кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акчаны файдалану өчен җаваплылык Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчесенә йөкләнә.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсендәге дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2013 ел, 31 июль, 538 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 17 март, 159 нчы; 2016 ел, 30 декабрь, 1056 нчы; 2017 ел, 18 сентябрь, 696 нчы; 2020 ел, 7 сентябрь, 793 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсендәге дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.4 пункт өстәргә:

«1.4. Фәнни учреждениеләр җитәкчеләре:

ел саен фәнни учреждениеләр хезмәткәрләре өчен тарификацияле исемлекләр төзи һәм аларны раслый;

фәнни учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмнәрен үз вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җавап бирә.»;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.12 пункт өстәргә:

«5.12. Фәнни учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында «баш фәнни хезмәткәр», «төп фәнни хезмәткәр», «өлкән фәнни хезмәткәр», «фәнни хезмәткәр», «кече фәнни хезмәткәр» вазифаларын биләүче хезмәткәрләргә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

8 бүлектә:

исемендә «формалаштыру» сүзеннән соң «һәм алардан файдалану» сүзләрен өстәргә;

8.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.1. Фәнни учреждениенең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына фәнни учреждениенең хезмәтләр күрсәтү нормативлары, күрсәтелә торган хезмәтләр саны нигезендә билгеләнгән акча күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм фәнни учреждениенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 8.5 пункт өстәргә:

«8.5. Бу Нигезләмәдә билгеләнгән хезмәт окладларын, компенсация, стимул бирү һәм социаль характердагы түләүләрне исәпләү фәнни учреждениеләр хезмәткәрләренә (эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм

хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен кертеп) фәнни оешманың финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында фәнни учреждениеләрнең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча фәнни учреждениеләрнең бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы булганда, кызыксындыру характерындагы түләүләр кайсы вазифаларның һөнәр-квалификация төркеме буенча хезмәт өчен түләү фондында экономияләнгән акча барлыкка килгән булса, шул вазифалар төркемендәге хезмәткәрләргә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен кертеп) түләнә.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән фәнни учреждениеләрнең хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәренә (фәнни учреждениенең «баш фәнни хезмәткәр», «төп фәнни хезмәткәр», «өлкән фәнни хезмәткәр», «фәнни хезмәткәр», «кече фәнни хезмәткәр» вазифаларын биләүче хезмәткәрләреннән һәм җитәкчесеннән тыш) әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.

Фәнни учреждение җитәкчесенә хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән кызыксындыру характерындагы түләү күләме фәнни учреждениенең гамәлгә куючысы тарафыннан билгеләнә.

Фәнни учреждениенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында хезмәт өчен түләү фондында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәре кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акчаны файдалану өчен җаваплылык фәнни учреждение җитәкчесенә йөкләнә.».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 965 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1262 нче; 2019 ел, 6 май, 380 нче; 2019 ел, 11 июль, 565 нче; 2019 ел, 28 август, 714 нче; 2019 ел, 2 ноябрь, 1008 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1278 нче; 2020 ел, 16 апрель, 294 нче; 2020 ел, 21 май, 413 нче, 2020 ел, 1 сентябрь, 772 нче; 2020 ел, 23 октябрь, 954 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

VI бүлекнең 14.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14.3. Гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәр-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Гомуми белем бирү оешмасының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм аннан файдалану тәртибе

1. Гомуми белем бирү оешмасының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына гомуми белем бирү оешмасының хезмәтләр күрсәтү нормативлары, күрсәтелә торган хезмәтләр саны нигезендә билгеләнгән акча күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм гомуми белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

2. Бу Нигезләмәдә билгеләнгән хезмәт окладларын, компенсация, стимул бирү һәм социаль характердагы түләүләрне исәпләү гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен кертеп) гомуми белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында фәнни учреждениеләрнең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча гомуми белем бирү оешмасының бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы булганда, кызыксындыру характерындагы түләүләр кайсы вазифаларның һөнәр-квалификация төркеме буенча хезмәт өчен түләү фондында экономияләнгән акча барлыкка килгән булса, шул вазифалар төркемендәге хезмәткәрләргә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен кертеп) түләнә.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән гомуми белем бирү оешмасының хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәренә (гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесеннән, педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен биләүче хезмәткәрләреннән тыш) әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен

түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.

Гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенә хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән кызыксындыру характерындагы түләү күләме гомуми белем бирү оешмасының гамәлгә куючысы тарафыннан билгеләнә.

Гомуми белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында хезмәт өчен түләү фондында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәре кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акчаны файдалану өчен җаваплылык гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

V бүлекнең 13.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13.3. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәр-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

VIII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

### «VIII. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм аннан файдалану тәртибе

1. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына мәктәпкәчә белем бирү оешмасының хезмәтләр күрсәтү нормативлары, күрсәтелә торган хезмәтләр саны нигезендә билгеләнгән акча күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

2. Бу Нигезләмәдә билгеләнгән хезмәт окладларын, компенсация, стимул бирү һәм социаль характердагы түләүләрне исәпләү мәктәпкәчә белем бирү оешмасы хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен кертеп) мәктәпкәчә белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча мәктәпкәчә белем бирү оешмасының бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы булганда, кызыксындыру характерындагы түләүләр кайсы вазифаларның һөнәр-квалификация төркеме буенча хезмәт өчен түләү фондында экономияләнгән акча барлыкка килгән булса, шул вазифалар төркемендәге хезмәткәрләргә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен кертеп) түләнә.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән мәктәпкәчә белем бирү оешмасының хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәренә (мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесеннән, педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен биләүче хезмәткәрләреннән тыш) әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән кызыксындыру характерындагы түләү күләме мәктәпкәчә белем бирү оешмасының гамәлгә куючысы тарафыннан билгеләнә.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында хезмәт өчен түләү фондында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәре кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акчаны файдалану өчен җаваплылык мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмаларының хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

VI бүлекнең 6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәр-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Өстәмә белем бирү оешмаларында хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм аннан файдалану тәртибе

1. Өстәмә белем бирү оешмаларында хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына өстәмә белем бирү оешмасының финанс чыгымнары нормативлары, кулланучылар һәм хезмәт күрсәтүләр саны нигезендә билгеләнгән акча күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм өстәмә белем бирү оешмаларында финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

2. Бу Нигезләмәдә билгеләнгән хезмәт окладларын, компенсация, стимул бирү һәм социаль характердагы түләүләрне исәпләү өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмасы хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен кертеп) өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмасының бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы булганда, кызыксындыру характерындагы түләүләр кайсы вазифаларның һөнәр-квалификация төркеме буенча хезмәт өчен түләү фондында экономияләнгән акча барлыкка килгән булса, шул вазифалар төркемендәге хезмәткәрләргә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен кертеп) түләнә.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмасының хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәренә (өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмасы җитәкчесеннән, педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен биләүче хезмәткәрләреннән тыш) әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.

Өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмасы җитәкчесенә хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән кызыксындыру характерындагы түләү күләме өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмасының гамәлгә куючысы тарафыннан билгеләнә.

Өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында хезмәт өчен түләү фондында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәре кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акчаны файдалану өчен җаваплылык өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

VI бүлекнең 6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә

ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында «производствода эшләргә өйрәтү мастеры», «укытучы (профессор-укытучы составына кертелгән укытучылар вазифаларыннан башка)», «тормыш иминлеге нигезләрен оештыручы укытучы», «тренер-укытучы», «тренер» вазифаларын хезмәткәрләргә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Һөнәри белем бирү оешмаларының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм аннан файдалану тәртибе

1. Һөнәри белем бирү оешмаларының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына һөнәри белем бирү оешмаларының хезмәтләр күрсәтү нормативлары, күрсәтелә торган хезмәтләр саны нигезендә билгеләнгән акча күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм һөнәри белем бирү оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

2. Бу Нигезләмәдә билгеләнгән хезмәт окладларын, компенсация, стимул бирү һәм социаль характердагы түләүләрне исәпләү һөнәри белем бирү оешмасы хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен кертеп) һөнәри белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында һөнәри белем бирү оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча һөнәри белем бирү оешмасының бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы булганда, кызыксындыру характерындагы түләүләр кайсы вазифаларның һөнәр-квалификация төркеме буенча хезмәт өчен түләү фондында экономияләнгән акча барлыкка килгән булса, шул вазифалар төркемендәге хезмәткәрләргә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен кертеп) түләнә.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән һөнәри белем бирү оешмасының хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәренә (һөнәри белем бирү оешмасының «производствода эшләргә өйрәтү мастеры», «укытучы (профессор-укытучы составына кертелгән укытучылар вазифаларыннан башка)», «тормыш иминлеге нигезләрен оештыручы укытучы», «тренер-укытучы», «тренер» вазифаларыннан, җитәкчесеннән башка) әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характе-

рындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.

Һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесенә хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән кызыксындыру характерындагы түләү күләме һөнәри белем бирү оешмасының гамәлгә куючысы тарафыннан билгеләнә.

Һөнәри белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында хезмәт өчен түләү фондында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәре кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акчаны файдалану өчен җаваплылык өстәмә белем бирү буенча һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының югары белем бирә торган мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү буенча дәүләт мәгариф оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

V бүлекнең 5.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5.4.1 пунктча өстәргә:

«5.4.1. Татарстан Республикасының югары белем бирә торган мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү буенча дәүләт мәгариф оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында профессор-укытучы составы вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен биләүче хезмәткәрләргә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

VIII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VIII. Татарстан Республикасының югары белем бирә торган мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү буенча дәүләт мәгариф оешмаларының һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм аннан файдалану тәртибе

8.1. Татарстан Республикасының югары белем бирә торган мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү буенча дәүләт мәгариф оешмаларының һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларының хезмәт өчен түләү фонды агымдагы финанс елына норматив чыгымнар, күрсәтелә торган хезмәтләр саны нигезендә билгеләнә торган акча күләме чикләрендә формалаштырыла һәм Татарстан Республикасының югары белем бирә

торган мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү буенча дәүләт мәгариф оешмаларының һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылыш таба.

8.2. Бу Нигезләмәдә билгеләнгән хезмәт окладларын, компенсация һәм стимул бирү характерындагы түләүләрне исәпләү Татарстан Республикасының югары белем бирә торган мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү буенча дәүләт мәгариф оешмасының һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында агымдагы финанс елында хезмәт өчен түләүгә каралган акча исәбеннән Татарстан Республикасының югары белем бирә торган мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү буенча дәүләт мәгариф оешмасы һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен кертеп) гамәлгә ашырыла.

8.3. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында Татарстан Республикасының югары белем бирә торган мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү буенча дәүләт мәгариф оешмаларының һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын яки бюджет сметасын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча мәктәпкәчә белем бирү оешмасының бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы булганда, кызыксындыру характерындагы түләүләр кайсы вазифаларның һөнәр-квалификация төркеме буенча хезмәт өчен түләү фондында экономияләнгән акча барлыкка килгән булса, шул вазифалар төркемендәге хезмәткәрләргә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен кертеп) түләнә.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән Татарстан Республикасының югары белем бирә торган мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү буенча дәүләт мәгариф оешмаларының һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларының хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәренә (Та-

тарстан Республикасының югары белем бирә торган мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү буенча дәүләт мәгариф оешмаларының һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларының профессор-укытучы составы вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен биләүче хезмәткәрләреннән, җитәкчесеннән тыш) әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.

Татарстан Республикасының югары белем бирә торган мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү буенча дәүләт мәгариф оешмасы һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары җитәкчесенә хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән кызыксындыру характерындагы түләү күләме Татарстан Республикасының югары белем бирә торган мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү буенча дәүләт мәгариф оешмасының һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларының гамәлгә куючысы тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасының югары белем бирә торган мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү буенча дәүләт мәгариф оешмасының һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында хезмәт өчен түләү фондында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәре кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акчаны файдалану өчен җаваплылык Татарстан Республикасының югары белем бирә торган мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү буенча дәүләт мәгариф оешмасы һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары җитәкчесенә йөкләнә.»;

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 413 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 30 декабрь, 1245 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләре һәм мәдәният-ял итү учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.5 пункт өстәргә:

«1.5. Татарстан Республикасының дәүләт китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләре һәм мәдәният-ял итү учреждениеләре җитәкчеләре:

белем алу һәм эш (белгечлек буенча, билгеле бер вазифада эшләү) стажы турындагы документларны һәм дәүләт китапханәләре, музейлар, музей тибындагы дәүләт учреждениеләре һәм мәдәният-ял итү учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренең хезмәт хакы ставкалары (хезмәт окладлары) күләмнәре билгеләнә торган башка нигезләрне тикшерә;

ел саен дәүләт китапханәләре, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләр һәм мәдәният-ял итү учреждениеләренең барлык хезмәткәрләре өчен тарификацияле исемлекләр төзи һәм аларны раслый;

дәүләт китапханәләре, музейлар, музей тибындагы башка учреждениеләр һәм мәдәният-ял итү учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмнәрен үз вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җавап бирә.»;

IV бүлектә:

4.8 пунктның 2 нче таблицасындагы 1 графада «баш» сүзеннән соң «яки төп» сүзләрен өстәргә;

4.17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.17. Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләре һәм мәдәният-ял учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында мәдәният хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

V бүлектә:

5.4 пунктның 5 нче таблицасында:

2 графада «кеше» сүзен «ставка» сүзенә алмаштырырга;

3 графада «10 га кадәр» сүзләрен «11 гә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

5.6 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

VII бүлектә:

исемендә «формалаштыру» сүзеннән соң «һәм алардан файдалану» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 7.2, 7.3 пунктлар өстәргә:

«7.2. Бу Нигезләмәдә билгеләнгән хезмәт окладларын, компенсация, стимул бирү һәм социаль характердагы түләүләрне исәпләү дәүләт китапханәләре, музейлары, музей тибындагы дәүләт учреждениеләре һәм мәдәният-ял итү учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренә мәдәният учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

7.3. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләре һәм мәдәният-ял итү учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле

хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләре һәм мәдәният-ял итү учреждениеләренең бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы булганда, кызыксындыру характерындагы түләүләр кайсы вазифаларның һөнәр-квалификация төркеме буенча хезмәт өчен түләү фондында экономияләнгән акча барлыкка килгән булса, шул вазифалар төркемендәге хезмәткәрләргә түләнә.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләре, музейлары, музей тибындагы дәүләт учреждениеләре һәм мәдәният-ял итү учреждениеләре җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре гомумтармак вазифаларының һәм эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һөнәр-квалификация төркемнәрендәге хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәрләренә әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләре һәм мәдәният-ял итү учреждениеләре җитәкчеләренә кызыксындыру характерындагы түләү күләме Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләре һәм мәдәният-ял итү учреждениеләренең гамәлгә куючысы тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләре һәм мәдәният-ял итү учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында хезмәт өчен түләү фондында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәре кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акчаны файдалану өчен җаваплылык Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләре һәм мәдәният-ял итү учреждениеләре җитәкчесенә йөкләнә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының башкару сәнгать буенча дәүләт учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

I бүлектә:

1.2 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт өчен түләү системасы – учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен (база окладлары, хезмәт окладлары күләмнәрен

кертеп), шулай ук федераль законнар, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм стимул бирү характерындагы түләүләрне билгели торган нормалар җыелмасы;»;

түбәндәге эчтәлекле 1.5 пункт өстәргә:

«1.5. Татарстан Республикасының башкару сәнгате буенча дәүләт учреждениеләре җитәкчеләре:

белем алу һәм эш (белгечлек буенча, билгеле бер вазифада эшләү) стажы турындагы документларны һәм башкару сәнгате буенча дәүләт учреждениеләрендәге барлык хезмәткәрләрнең хезмәт хакы ставкалары (хезмәт окладлары) күләмнәре билгеләнә торган башка нигезләрне тикшерә;

ел саен башкару сәнгате буенча дәүләт учреждениеләренең барлык хезмәткәрләре өчен тарификацияле исемлекләр төзи һәм аларны раслый;

башкару сәнгате буенча дәүләт учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмнәрен үз вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җавап бирә.»;

II бүлектә «Мәдәният, сәнгать һәм кинематографиянең урта звено хезмәткәрләре вазифалары» һөнәр-квалификация төркеме» сүзләрен «Башкару сәнгатенең урта звено хезмәткәрләре вазифалары» һөнәр-квалификация төркеме» сүзләренә алмаштырырга;

IV бүлектә:

4.9 пунктта «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» сүзләреннән соң «, «Мгновение» бию театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе» сүзләрен өстәргә;

4.17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.17. Татарстан Республикасының башкару сәнгате буенча дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында башкару сәнгате хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

V бүлектә:

5.4 пунктның 5 нче таблицасында:

2 графада «кеше» сүзен «ставка» сүзенә алмаштырырга;

3 графада «10 га кадәр» сүзләрен «11 гә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

5.6 пункт үз көчен югалткан дип таныргa;

VII бүлектә:

исемендә «формалаштыру» сүзеннән соң «һәм алардан файдалану» сүзләрен өстәргә;

7.1 пунктта «башкару сәнгате» сүзләрен «башкару сәнгате буенча дәүләт учреждениеләре» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 7.2, 7.3 пунктлар өстәргә:

«7.2. Бу Нигезләмәдә билгеләнгән хезмәт окладларын, компенсация, стимул бирү һәм социаль характердагы түләүләрне исәпләү башкару сәнгате буенча дәүләт

учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренә башкару сәнгате учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

7.3. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында Татарстан Республикасы башкару сәнгате учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча Татарстан Республикасы башкару сәнгате учреждениеләренең локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы булганда, кызыксындыру характерындагы түләүләр кайсы вазифаларның һөнәр-квалификация төркеме буенча хезмәт өчен түләү фондында экономияләнгән акча барлыкка килгән булса, шул вазифалар төркемендәге хезмәткәрләргә түләнә.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән Татарстан Республикасы башкару сәнгате учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һәм эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һөнәр-квалификация төркемнәрендәге хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәрләренә әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.

Татарстан Республикасының башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән кызыксындыру характерындагы түләү күләмеТатарстан Республикасы башкару сәнгате учреждениесенең гамәлгә куючысы тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы башкару сәнгате учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында хезмәт өчен түләү фондында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәре кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акчаны файдалану өчен җаваплылык Татарстан Республикасының башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә йөкләнә.»;

әлеге Нигезләмәнең кушымтасында:

1 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 1.3, 1.4 пунктлар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1.3. | Россия Федерациясенең атказанган артисты |
| 1.4. | Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре»; |

2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.4, 2.5 пунктлар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2.4. | Татарстан Республикасының атказанган артисты |
| 2.5. | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазифалары һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

I бүлекнең 1.2 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт өчен түләү системасы – учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен (база окладлары, хезмәт окладлары күләмнәрен кертеп), шулай ук федераль законнар, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм стимул бирү характерындагы түләүләрне билгели торган нормалар җыелмасы;»;

IV бүлекнең 4.17 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.17. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләре һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең IV бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 4.9 пункт өстәргә:

«4.9. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең һөнәр-квалификация төркеме хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифалары һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

I бүлекнең 1.2 пунктында:

беренче – икенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт өчен түләү системасы – учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен (база окладлары, хезмәт окладлары күләмнәрен кертеп), шулай ук федераль законнар, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм стимул бирү характерындагы түләүләрне билгели торган нормалар җыелмасы;

база оклады, хезмәт хакының база ставкасы – тиешле һөнәр-квалификация төркеменә керүче эшче һөнәре яки җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазифасы буенча һөнәри эшчәнлек гамәлгә ашыручы учреждение хезмәткәренең компенсация

һәм стимул бирү характерындагы түләүләр исәпкә алынмаган оклады, хезмәт хакы ставкасы;»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәткәрнең хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү) – хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм шартларына карап, хезмәт өчен бүләкләү, шулай ук компенсация һәм стимул бирү характерындагы түләүләр;»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифалары һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең IV бүлегендәге 4.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.13. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифалары һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең мәгариф хезмәткәрләре вазифалары һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

IV бүлекнең 4.17 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.17. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең мәдәният хезмәткәрләре вазифалары һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

әлеге Нигезләмәнең кушымтасында:

1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.3 – 1.5 пунктлар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1.3. | Россия Федерациясенең атказанган артисты |
| 1.4. | Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.5. | Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе»; |

2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.4 – 2.6 пунктлар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2.4. | Татарстан Республикасының атказанган артисты |
| 2.5. | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 2.6. | Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифалары һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең IV бүлегендәге 4.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.11. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән, ирешелгән максатчан күрсәткечләр дәрәҗәсен саклап калу максатларында Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифалары һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.».

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте буенча дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 14 август, 665 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 21 июнь, 505 нче; 2020 ел, 31 гыйнвар, 54 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте буенча дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы ведомство буйсынуындагы бертип булмаган кайбер оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. Татарстан Республикасының яшьләр сәясәте буенча дәүләт оешмалары җитәкчеләре:

белем алу һәм эш (белгечлек буенча, билгеле бер вазифада эшләү) стажы турындагы документларны һәм хезмәткәрләрнең хезмәт окладлары күләмнәре билгеләнә торган башка нигезләрне тикшерә;

ел саен Татарстан Республикасының яшьләр сәясәте буенча дәүләт оешмалары хезмәткәрләре өчен тарификацияле исемлекләр төзи һәм аларны раслый;

Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте буенча дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмнәрен үз вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җавап бирә.»;

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Яшьләр сәясәте оешмаларында хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм аннан файдалану тәртибе

1. Яшьләр сәясәте оешмаларында хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына яшьләр сәясәте оешмаларының финанс чыгымнары нормативы, кулланучылар һәм хезмәт күрсәтүләр саны нигезендә билгеләнгән акча күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм яшьләр сәясәте оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында яки бюджет сметасында чагылдырыла.

2. Бу Нигезләмәдә билгеләнгән хезмәт окладларын, компенсация, стимул бирү һәм социаль характердагы түләүләрне исәпләү Татарстан Республикасының яшьләр сәясәте буенча дәүләт оешмалары хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм

хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен кертеп) Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте буенча дәүләт оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында яки бюджет сметасында агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында яшьләр сәясәте оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча яшьләр сәясәте оешмаларының бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы булганда, кызыксындыру характерындагы түләүләр кайсы вазифаларның һөнәр-квалификация төркеме буенча хезмәт өчен түләү фондында экономияләнгән акча барлыкка килгән булса, шул вазифалар төркемендәге хезмәткәрләргә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен кертеп) түләнә.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән яшьләр сәясәте оешмаларының хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәренә (яшьләр сәясәте оешмасы җитәкчесеннән тыш) әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.

Яшьләр сәясәте оешмасы җитәкчесенә хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән кызыксындыру характерындагы түләү күләме яшьләр сәясәте оешмасының гамәлгә куючысы тарафыннан билгеләнә.

Яшьләр сәясәте оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында хезмәт өчен түләү фондында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәре кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акчаны файдалану өчен җаваплылык яшьләр сәясәте оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.».

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 15 август, 671 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 15 апрель, 290 нчы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. Дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары җитәкчеләре:

белем алу һәм эш (белгечлек буенча, билгеле бер вазифада эшләү) стажы турындагы документларны һәм хезмәткәрләрнең хезмәт окладлары күләмнәре билгеләнә торган башка нигезләрне тикшерә;

ел саен дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләре өчен тарификацияле исемлекләр төзи һәм аларны раслый;

дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмнәрен үз вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җавап бирә.»;

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм аннан файдалану тәртибе

1. Дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларының финанс чыгымнары нормативы, кулланучылар һәм хезмәт күрсәтүләр саны нигезендә билгеләнгән акча күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларында финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

2. Бу Нигезләмәдә билгеләнгән хезмәт окладларын, компенсация, стимул бирү һәм социаль характердагы түләүләрне исәпләү Татарстан Республикасы дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен кертеп) Татарстан Республикасы дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында яки бюджет сметасында агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларының бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы булганда, кызыксындыру характерындагы түләүләр кайсы вазифаларның һөнәр-квалификация төркеме буенча хезмәт өчен түләү фондында экономияләнгән акча барлыкка килгән булса, шул вазифалар төркемендәге хезмәткәрләргә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен кертеп) түләнә.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларының хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәренә (дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары җитәкчеләреннән тыш) әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.

Дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары җитәкчеләренә хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбенә кызыксындыру характерындагы түләү күләме дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларының гамәлгә куючысы тарафыннан билгеләнә.

Дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында хезмәт өчен түләү фондында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәре кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акчаны файдалану өчен җаваплылык дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары җитәкчеләренә йөкләнә.».

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 25 сентябрь, 853 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 6 май, 380 нче; 2020 ел, 16 апрель, 294 нче; 2020 ел, 1 сентябрь, 768 нче; 2020 ел, 3 ноябрь, 989 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. Спорт резервын әзерләү оешмалары җитәкчеләре:

белем алу һәм эш (белгечлек буенча, билгеле бер вазифада эшләү) стажы турындагы документларны һәм хезмәткәрләрнең хезмәт окладлары күләмнәре билгеләнә торган башка нигезләрне тикшерә;

ел саен спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләре өчен тарификацияле исемлекләр төзи һәм аларны раслый;

спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмнәрен үз вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җавап бирә.»;

VI бүлекнең 7.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 17 октябрендәге б-2245 номерлы боерыгы белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә спорт резервы әзерлеге концепциясен тормышка ашыру чаралары планын үтәгәндә спорт резервы әзерлеге оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру максатларында педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәр-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә һәм икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләү бирелергә мөмкин.»;

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Спорт резервын әзерләү оешмаларының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм аннан файдалану тәртибе

1. Спорт резервын әзерләү оешмасының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына спорт резервын әзерләү оешмасының финанс

чыгымнары нормативы, кулланучылар һәм хезмәт күрсәтүләр саны нигезендә билгеләнгән акча күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм спорт резервын әзерләү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

2. Бу Нигезләмәдә билгеләнгән хезмәт окладларын, компенсация, стимул бирү һәм социаль характердагы түләүләрне исәпләү спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен кертеп) спорт резервын әзерләү оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында яки бюджет сметасында агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында спорт резервын әзерләү оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча спорт резервын әзерләү оешмасының бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы булганда, кызыксындыру характерындагы түләүләр кайсы вазифаларның һөнәр-квалификация төркеме буенча хезмәт өчен түләү фондында экономияләнгән акча барлыкка килгән булса, шул вазифалар төркемендәге хезмәткәрләргә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен кертеп) түләнә.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән спорт резервы әзерлеге оешмасының хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәренә (спорт резервы әзерлеге оешмасының педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәр-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләреннән һәм икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәр-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләреннән, җитәкчесеннән тыш) әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.

Спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесенә хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән кызыксындыру характерындагы түләү күләме спорт резервын әзерләү оешмасының гамәлгә куючысы тарафыннан билгеләнә.

Спорт резервын әзерләү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында хезмәт өчен түләү фондында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәре кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акчаны файдалану өчен җаваплылык спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.».

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт архивлары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2019 ел, 9 август, 663 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт архивлары хезмәткәрләре вазифалары һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәр-

ләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.5 пункт өстәргә:

«1.5. Татарстан Республикасы дәүләт архивлары җитәкчеләре:

белем алу турындагы документларны һәм эш (белгечлек буенча, билгеле бер вазифада эшләү) стажын һәм архивлар хезмәткәрләрнең хезмәт хакы ставкалары (хезмәт окладлары) күләмнәре билгеләнә торган башка нигезләрне тикшерә;

ел саен архивлар хезмәткәрләре өчен тарификацияле исемлекләр төзи һәм аларны раслый;

архивлар хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмнәрен үз вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җавап бирә.»;

VII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VII. Дәүләт архивларының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм аннан файдалану тәртибе

7.1. Татарстан Республикасы дәүләт архивларының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы дәүләт архивларының финанс чыгымнары нормативы, кулланучылар һәм хезмәт күрсәтүләр саны нигезендә билгеләнгән акча күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм Татарстан Республикасы дәүләт архивларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

7.2. Бу Нигезләмәдә билгеләнгән хезмәт окладларын, компенсация, стимул бирү һәм социаль характердагы түләүләрне исәпләү дәүләт архивлары хезмәткәрләренә (эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен кертеп) дәүләт архивларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

7.3. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында дәүләт архивларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча дәүләт архивларының бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы булганда, кызыксындыру характерындагы түләүләр кайсы вазифаларның һөнәр-квалификация төркеме буенча хезмәт өчен түләү фондында экономияләнгән акча барлыкка килгән булса, шул вазифалар төркемендәге хезмәткәрләргә (эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен кертеп) түләнә.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән дәүләт архивының хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәренә (дәүләт архивы җитәкчесеннән тыш) әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.

Дәүләт архивы җитәкчесенә хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән кызыксындыру характерындагы түләү күләме дәүләт архивының гамәлгә куючысы тарафыннан билгеләнә.

Дәүләт архивларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында хезмәт өчен түләү фондында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәре кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акчаны файдалану өчен дәүләт архивы җитәкчесенә йөкләнә.».

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2019 ел, 1 ноябрь, 998 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 6 июль, 553 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1237 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. Кайбер мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмалары җитәкчеләре:

белем алу һәм педагогик эш (белгечлек буенча, билгеле бер вазифада эшләү) стажы турындагы документларны һәм педагогик хезмәткәрләрнең хезмәт хакы ставкалары (хезмәт окладлары) күләмнәре билгеләнә торган башка нигезләрне тикшерә;

ел саен хезмәткәрләр өчен тарификацияле исемлекләр төзи һәм аларны раслый;

хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләмнәрен үз вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җавап бирә.»;

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Кайбер мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмаларының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм аннан файдалану тәртибе

«1. Кайбер мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмаларының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына норматив чыгымнарны, хезмәт күрсәтүләр күләмнәрен исәпкә алып билгеләнгән акча күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм кайбер мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

2. Бу Нигезләмәдә билгеләнгән хезмәт окладларын, компенсация, стимул бирү һәм социаль характердагы түләүләрне исәпләү кайбер мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмалары хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен кертеп) кайбер мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында кайбер мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү

барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча кайбер мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмаларының бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы булганда, кызыксындыру характерындагы түләүләр кайсы вазифаларның һөнәр-квалификация төркеме буенча хезмәт өчен түләү фондында экономияләнгән акча барлыкка килгән булса, шул вазифалар төркемендәге хезмәткәрләргә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен кертеп) түләнә.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән кайбер мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмаларының хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәренә (кайбер мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмалары җитәкчеләреннән, педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен биләүче хезмәткәрләреннән тыш) әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.

Кайбер мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән кызыксындыру характерындагы түләү күләме кайбер мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмаларының гамәлгә куючысы тарафыннан билгеләнә.

Кайбер мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында хезмәт өчен түләү фондында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәре кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акчаны файдалану өчен кайбер мәгариф, спорт һәм яшьләр оешмалары җитәкчеләренә йөкләнә.».

11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2021 ел, 16 февраль, 84 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 8 июнь, 436 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.4, 1.5 пунктлар өстәргә:

«1.4. Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре җитәкчеләре:

белем алу турындагы документларны һәм эш (белгечлек буенча, билгеле бер вазифада эшләү) стажын һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы ставкалары (хезмәт окладлары) күләмнәре билгеләнә торган башка нигезләрне тикшерә;

ел саен халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре өчен тарификацияле исемлекләр төзи һәм аларны раслый;

халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмнәрен үз вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җавап бирә.

1.5. Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренең гамәлгә куючылары ел саен ел башына халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре җитәкчеләренең хезмәт окладларын раслый.»;

VIII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VIII. Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм алардан файдалану тәртибе

8.1. Татарстан Республикасының казна учреждениеләре булып торган халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләрендә хезмәт өчен түләү фонды агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән учреждениенең иң чик штат саныннан, бу Нигезләмәдә билгеләнгән хезмәт окладлары, стимул һәм компенсация бирү характерындагы түләүләр күләмнәреннән чыгып билгеләнгән акча күләме чикләрендә формалаштырыла һәм тиешле казна учреждениесенең бюджет сметасында чагылдырыла.

8.2. Бу Нигезләмәдә билгеләнгән хезмәт окладларын, компенсация, стимул бирү һәм социаль характердагы түләүләрне исәпләү халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә (эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен кертеп) халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренең бюджет сметасында агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

8.3. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренең бюджет сметасын үтәү барышында экономияләнеп барлыкка килгән акча Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренең бу Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы булганда, кызыксындыру характерындагы түләүләр кайсы вазифаларның һөнәр-квалификация төркеме буенча хезмәт өчен түләү фондында экономияләнгән акча барлыкка килгән булса, шул вазифалар төркемендәге хезмәткәрләргә (эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен кертеп) түләнә.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренең хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәренә (Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте җитәкчесеннән тыш) әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән кызыксындыру характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең

минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.

Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре җитәкчеләренә хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән кызыксындыру характерындагы түләү күләме Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесенең гамәлгә куючысы тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесенең бюджет сметасын үтәү барышында хезмәт өчен түләү фондында экономияләнеп барлыкка килгән акчаны файдалану өчен Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе җитәкчесенә йөкләнә.».

12. Бу карарның гамәле 2021 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин